ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.08.2024 Балык Бистәсе штп. № 212пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.05.2021 № 96пи карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән дип танылган затныкы булган күчемсез мөлкәтне читләштерү (шул исәптән алмашу яисә бүләк итү) буенча алыш-бирешләрне башкаруга опекунга (попечительгә) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.12.2020 ел, №509-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 11.02.2022 ел, №28пи карарына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.05.2021 № 96пи карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән дип танылган затныкы булган күчемсез мөлкәтне читләштерү (шул исәптән алмашу яисә бүләк итү) буенча алыш-бирешләрне башкаруга опекунга (попечительгә) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан кисәтү (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәтләр алдан (проактив) режимда Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi.tatar.ru/) яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/), техник мөмкинлекне гамәлгә ашыру юлы белән мөрәҗәгать итүче алдан аңа әлеге муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү турында гариза биргән очракта һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә чаралар башкарылганнан соң күрсәтелә.»;

1.2) 2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Муниципаль хезмәтне алдан күрсәтү (проактив) режимда республика порталы аша күрсәткән очракта регламентның әлеге пунктында каралган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында булган һәм Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә алынган белешмәләр файдаланыла.»;

1.3) 3 пунктның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә карата күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары бар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов